| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 04.07.2025 | №_527-п |

Саба муниципаль районы территориясендә ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеген раслау турында

1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы «Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» Федераль законның 17.4 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 3 декабрендәге 1092 номерлы «Ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеген раслау турында» карары белән, Татарстан Республикасынын 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы «Иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Законының 3 статьясындагы 4 өлешенең 2.3 пунктын үтәү өчен Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелә торган ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеген расларга.

2. Добро.Центру «Добрые Сабы» иреклелек (волонтерлык) үсеше өлкәсендәге «ДОБРО.РФ» бердәм мәгълүмат системасында ярдәмнең гамәлгә ашырыла торган чаралары турында мәгълүматны үз вакытында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы И. Р. Гариповка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетынын
№_____"___" ________________________
Карарына Кушымта.

**Саба муниципаль районы территориясендә ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары**

| № т/б | Ярдәм чаралары аталышы | Ярдәм чаралары күрсәтүче хакимият органы |
|---|---|---|
| | **1.Финанс ярдәме** | |
| **1.1** | «2020-2025 елларга Саба муниципаль районында волонтерлык хәрәкәтен үстерү» программасы нигезендә ирекләлек (волонтерлык) үсешенә ресурс ярдәме. | Татарстан Республикасы Саба МР Башкарма комитеты, Саба МР башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, Татарстан Республикасы Саба МР «Яшьлек» ЯҮ МБУ |
| | **2.Оештыру эшендә ярдәм** | |
| **2.1** | Саба муниципаль районы администрациясе башлыгының Рәхмәт хатлары | ТР Саба МР Башкарма комитеты, Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| **2.2** | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының ирекле (волонтерлык) берләшмәсе тарафыннан чаралар (форумнар, слетлар, семинарлар) үткәрү | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «ТР Саба МР Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Яшьлек» ЯҮ МБУ, Добро.Центр «Добрые Сабы» |
| **2.3** | Ирекле (волонтерлык) оешмалары чараларын оештыру һәм уздыру өчен урыннар (мәйданчыклар) бирү | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, ТР Саба МР Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, ТР Саба МР “Яшьлек” ЯҮ МБУ, Добро.Центр «Добрые Сабы», Саба муниципаль районындагы Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау Министрлыгының социаль яклау Бүлеге, Саба МР Башкарма комитетының мәдәният Бүлеге |
| **2.4** | Ирекләләрнең (волонтерларның) җәмәгать эшлеклеләре белән тематик очрашуларын оештыру | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, ТР Саба МР Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, ТР Саба МР “Яшьлек” ЯҮ МБУ, Добро.Центр «Добрые Сабы» |
| **2.5** | Россиядә ирекләләр (волонтер) көнен бәйрәм итүгә багышланган муниципаль тантаналы чара оештыру һәм уздыру | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, ТР Саба МР Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, ТР Саба МР “Яшьлек” ЯҮ МБУ, Добро.Центр «Добрые Сабы», Саба МР Башкарма комитетының мәдәният Бүлеге, "Саба аграр көллияте" ДАҺББУ |

| | | |
|---|---|---|
| **2.6** | "Көмеш" ирекләләрнең (волонтерларның) төрле дәрәҗәдәге чараларда катнашуын оештыру | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, ТР Саба МР Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, ТР Саба МР “Яшьлек” ЯҮ МБУ, Добро.Центр «Добрые Сабы», Саба МР Башкарма комитетының мәдәният Бүлеге |
| **2.7** | Ирекләләрнең (волонтерларның) шәхси кенәгәләрен рәсмиләштерү | Добро.Центр «Добрые Сабы» |
| | **2. Мәгълүмати ярдәм** | |
| **3.1** | Агымдагы ирекле (волонтерлык) проектлар, чаралар турында мәгълүматны рәсми мәгълүмат ресурсларында, яшьләр бергәлекләре турында интернет челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында һәм ТВда урнаштыру | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, ТР Саба МР “Яшьлек” ЯҮ МБУ, «Саба дулкыннары» ТРК, «Саба таннары» газетасы редакциясе |
| | **4.Мөлкәти ярдәм** | |
| **4.1** | Ирекле (волонтерлык) оешмалары чараларын үткәрү өчен урыннар бирү | Саба МР “Яшьлек” ЯҮ МБУ, ТР Саба МР Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Саба МР Башкарма комитетының мәдәният Бүлеге, "Сабантуй" мәдәни-спорт комплексы |
| **4.2** | Ирекле (волонтерлык) оешмалары чараларын оештыру һәм уздыру өчен матди-техник тәэмин итү | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, «Яшьлек» ЯҮ МБУ |
| **4.3** | Добро.Центру «Добрые Сабы» биналарны түләүсез файдалануга бирү. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Яшьлек» ЯҮ МБУ |
| | **5. Консультация ярдәме** | |
| **5.1** | Ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыру, ирекле (волонтерлык) эшчәнлек өлкәсендәге конкурсларда катнашу мәсьәләләре буенча консультацияләр үткәрү | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Яшьлек» ЯҮ МБУ, Добро.Центр «Добрые Сабы» |
| | **6.Методик ярдәм** | |
| **6.1** | Семинарлар оештыру юлы белән ирекләлек (волонтерлык) өлкәсендә тәҗрибә алмашу өчен шартлар тудыру | Саба МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт Бүлеге, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Яшьлек» ЯҮ МБУ, Добро.Центр «Добрые Сабы» |